КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 30 декабрь г.Казань № 1510

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалар белән тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнарны раслау турында» 2021 ел, 6 сентябрь, 831 нче карары белән расланган 2021 елга «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Диспетчерлык үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениесе тарафыннан өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалар белән тәэмин итү буенча дәүләт эшенең күләменә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалар белән тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнарны раслау турында» 2021 ел, 6 сентябрь, 831 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 12 декабрь, 1314 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган 2022 елга «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Диспетчерлык үзәге»

Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениесе тарафыннан өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалар белән тәэмин итү буенча дәүләт эшенең күләменә, аны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Бу карарның гамәле 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 6 сентябрь, 831 нче карары белән расланды (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 30 декабрь, 1510 нчы карары редакциясендә)

2022 елга «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Диспетчерлык үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениесе тарафыннан өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалар белән тәэмин итү буенча дәүләт эшенең күләме

| Балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалар алучылар категориясе | Балаларның яше | Бер елга дәүләт эше күләме, бала көне | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | адаптацияләнгән сыек сөт катнашмасы | сөт | кефир | эремчек |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге ТРЗ-63 номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтада билгеләнгән җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнә торган яшәү минимумы күләменнән һәм мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсеннән түбәнрәк булган гаиләләрдә яшәүче өч яшькә кадәрге балалар;<br>балалар туклануы өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалар белән түләүсез тәэмин итү | 0 айдан 6 айга кадәр | 958 125 | - | - | - |
| | 6 айдан 1 елга кадәр | 4 593 160 | 4 593 160 | 4 593 160 | 4 593 160 |
| | 1 яшьтән 3 яшькә кадәр | - | 20 037 405 | 20 037 405 | 20 037 405 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| рәвешендә социаль ярдәм чарасы күрсәтелә торган авырулар исемлегенә керүче авырулары булган өч яшькә кадәрге балалар | | | | | |
| ВИЧ-инфекцияле авыру аналардан туган балалар һәм ВИЧ-инфекция белән авыручы балалар | 0 айдан 6 айга кадәр | 21 900 | - | - | - |